Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № I-5**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 22 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының даими комиссияләрен төзү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30, 32 статьялары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 28 мартындагы XXXVI-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Регламентының 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының түбәндәге даими комиссияләрен төзергә:

- бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссия;

-транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссия;

- социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссия;

- кология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссия;

- законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссия.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев